**МЕЖРЕГИОНАЛЬНАЯ ОЛИМПИАДА ШКОЛЬНИКОВ «ЮНИОР»**
**ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ**
**ЗАКЛЮЧИТЕЛЬНЫЙ ЭТАП**
**2023-2024 учебный год**
**4 КЛАСС**

**Таблица ответов**

| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **а** | | | **X** | | | | **X** | | **X** | | | | | | **X** | | | **X** | | ***X*** |
| **ә** | | | | | **X** | | | | | | | **X** | | **X** | | | **X** | | **X** | |
| **б** | | **X** | | **X** | | | | **X** | | | | | **X** | | | **X** | | | | |
| **в** | X | | | | | **X** | | | | **X** | **X** | | | | | | | | | |
| | ***задания по 1 баллу*** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

1.Яңгырау тартык авазлар гына кергән рәтне билгеләгез. (1 балл)
а) [ж],[м],[к],[р];
ә) [д],[м],[с],[н];
б) [т],[м],[ң],[н];
**в) [ж],[з],[д],[м].**

2. Сүз башында языла алмый торган хәрефләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (1 балл)
а) ж, һ, к;
ә) ә, ү, ө;
**б) ң, ъ, ь;**
в) ц, щ, ж.

3. Синонимнардан гына торган рәтне билгеләгез. (1 балл)
**а) суык, салкын;**
ә) җир, күк;
б) көн, төн;
в) әби, бабай.

4. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (1 балл)
- Габделбар, **кара,**
Шүрлектә **кара!** (Җәвад Тәрҗеманов)
а) антонимнар;
ә) синонимнар;
**б) омонимнар;**
в) күчерелмә мәгънәле сүзләр.

5. Тамырдаш сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез. (1 балл)
а) бал, бала;
**ә) бал, баллы;**
б) бал, балчык;
в) бал, балык.

6. Нокталар урынына куела торган кушымча дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (1 балл)

Дөнья... иң зур байлык – белем. (Мәкаль)

а) -ның;

ә) -га;

б) -дан;

**в) -да.**

7. *Без дә Тукайны яратабыз, аның* ***шигырьләрен*** *кызыксынып укыйбыз* (С. Шакир) җөмләсендә билгеләнгән сүз –

**а) төшем килешендә;**

ә) иялек килешендә;

б) юнәлеш килешендә;

в) баш килештә.

8. Хәзерге заман фигыль кулланылган мәкальне билгеләгез. (1 балл)

а) Төлке төнлә йөрер, көндез йоклар.

ә) Мәктәп – белем йорты.

**б) Төлке төшендә дә тавык саный.**

в) Мәскәү бер көндә төзелмәгән.

9. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (1 балл)

Ялкауның көн дә башы авырта. (Мәкаль)

**а) хикәя;**

ә) сорау;

б) боеру;

в) тойгылы.

10. *Бүген без сокланып карый торган Казан Кремле – бик* ***борынгы*** *корылма* җөмләсендә ***БОРЫНГЫ*** сүзе –

а) ия;

ә) хәл;

б) тәмамлык;

**в) аергыч.**

11. Басымы соңгы иҗеккә **төшмәгән** сүзне билгеләгез. (1 балл)

Имән чикләвеге алмагач төбенә тәгәрәми. (Мәкаль)

а) имән;

ә) чикләвеге;

б) алмагач;

**в) тәгәрәми.**

12. Кайсы рәттә һәрбер сүз баш хәрефтән язылырга тиеш? (1 балл)

а) кыз, авыл, шәһәр;

**ә) казан, мәскәү, габдулла;**

б) галиев, укучы, мәктәп;

в) елга, диңгез, сара.

13. Фигыль нәрсәне белдерә? (1 балл)

а) предметның билгесен;

ә) предметны;

**б) предметның эшен;**

в) предметның хәлен.

14. Керпе сүзенә түбәндәге кушымчаларның кайсысын ялгарга кирәк? (1 балл)
а) -дан;
**ә)- дән;**
в)- тан;
г) -тән;

15. Нәрсә ул җанландыру?(1 балл)
**а) әдәби әсәрләрдә җансыз, тере булмаган предметларны тере итеп күрсәтү, кешеләштерү алымы;**
ә) бик күп табигый күренешләрне күрсәтү алымы;
б)табигать һәм сәнгать телен сынландыру алымы;
в) әкиятләрдәге геройларның сөйләшүе;

16. Г.Тукайның туган көне кайчан? (1 балл)
а)1 апрель;
ә)15 февраль;
**б)26 апрель;**
в)9 май;

17.Муса Җәлил кем ул? (1 балл)
а)язучы;
**ә)герой-шагыйрь;**
б)композитор;
в)рәссам;

18. Мәкальне дәвам ит. (1 балл)
Кош канаты белән,
**а)кеше дуслары белән көчле;**
ә)иптәшең үзеңнән яхшы булсын:
б)дустың булмаса эзлә;
в)берсе дә туры килми.

19. Шигырьдән өзекне укы һәм авторын билгелә. (1 балл)
"— Ник газаплыйсың болай син,
мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр йә өч кенә."
а) Роберт Миңнуллин;
**ә) Габдулла Тукай;**
б) Шәүкәт Галиев;
в) Муса Җәлил.

20. Җәй башында кайсы бәйрәм була? (1 балл)
**а) Сабан туе;**
ә) Әниләр бәйрәме;
б) Ватанны саклаучылар бәйрәме;
в) Сөмбелә бәйрәме.

II. Нокталар урынына бармак "атамаларын" языгыз. (5 балл)
**Баш** бармак баш кашый,
**Имән** бармак имән ташый,
**Урта** бармак утын яра,
**Атсыз** бармак ат куа,
**Чәнти** бармак чәй эчә.

III.  Сүзләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. (10 балл)

| | |
|---|---|
| Снеговик – **Кар бабай** | коньки – **тимераяк** |
| Дед Мороз – **Кыш бабай** | ворота – **капка** |
| Снегурочка – **Кар кызы** | клюшка – **кәшәкә** |
| лыжи – **чаңгы** | шайба – **шәйба** |
| санки – **чана** | вратарь **– капкачы** |